Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге составына керүче
Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

« 28 » ноябрь 2023 ел № 108

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 100 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2023 елның 23 ноябрендә 14.00 сәг.Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы гражданнар җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай авылы җирлегенең Татар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?" дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде

- Татар Әхтиялы авылында кар чистарту;
- ташландык йорт яны территорияләрендә үлән чабуга хезмәт хакы түләү һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- урам яктырту җайланмасы-3данә;
- триммер сатып алу;
- Урман урамы буенча вак таш җәю;
- вак таштан соң юлны тигезләү

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 86 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 52 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ"  - 40 граждан тавыш бирде;

"ЮК"   - 12 граждан.

.

Бәян ителгәннәр нигезендә,  гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай авылы җирлегенең Татар Әхтиялы авылында  яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп,  алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?" дигән сорауга карарны танырга

- Татар Әхтиялы авылында кар чистарту;
- ташландык йорт яны территорияләрендә үлән чабуга хезмәт хакы түләү һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- урам яктырту җайланмасы-3данә;
- триммер сатып алу;
-Урман урамы буенча вак таш җәю;
- вак таштан соң юлны тигезләү

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru  һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Турай авыл җирлеге» бүлегендә  урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б. Куляшова